КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 апрель г.Казань № 318

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында балаларга цифрлы белем бирү үзәген оештыру чараларын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 2 июль, 528 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында балаларга цифрлы белем бирү үзәген оештыру чараларын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 2 июль, 528 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген оештыру һәм ачу буенча чаралар комплексын («юл картасы»н) яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Оештырыла торган «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге тасвирламасында (алга таба – Тасвирлама):

1 бүлекнең дүртенче абзацында «2021» саннарын «2020» саннарына алмаштырырга;

3 бүлекнең беренче абзацында «2021» саннарын «2020» саннарына алмаштырырга;

4 бүлегендәге 1 нче таблицадан соң бишенче абзацта «2021» саннарын «2020» саннарына алмаштырырга;

Тасвирламага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә

(карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 02 июль, 528 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 22 апрель, 318 нче карары редакциясендә)

## «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген оештыру һәм ачу буенча чаралар комплексы («юл картасы»)

| т/с | Чара исеме | Җаваплы | Нәтиҗә | Вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген булдыру һәм эшләтү өчен җаваплы төбәк ведомство проект офисы составында вазыйфаи затны раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2019 елның 25 августы |
| 2. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәгенең оештыру-хокукый формасын билгеләү, урнашу урыны; «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген булдыру турында хокукый актны һәм «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге эшчәнлеге турындагы нигезләмәне раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2019 елның 1 октябре |
| 3. | IT-куб» цифрлы белем бирү үзәгенең медиапланын раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2019 елның 15 октябре, алга таба – ел саен |
| 4. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген проектлау һәм зоналаштыру дизайн-проектын килештерү һәм раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Федераль оператор хаты һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы акты | 2019 елның 30 октябре |
| 5. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген булдыру һәм эшләтүгә партнерларны җәлеп итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, ведомство проект офисы һәм партнерлары арасында хезмәттәшлек | 2019 елның 1 ноябре |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | турында килешүләр | |
| 6. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген булдыру өчен укыту һәм тәрбия чаралары исемлеген формалаштыру һәм килештерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | Федераль оператор хаты һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | Федераль оператор җибәргән график нигезендә |
| 7. | Чираттагы финанс елына һәм план чорына «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген финанс белән тәэмин итүгә акчалар күләмнәре турында мәгълүмат тапшыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы хаты | 2019 елның 30 ноябре, алга таба – ел саен |
| 8. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген төзүгә җәлеп ителә торган бюджеттан тыш чаралар күләмнәре турында мәгълүмат тапшыру, чыгымнар статьялары буенча | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы хаты | 2019 елның 30 ноябре, алга таба – ел саен |
| 9. | «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешү төзү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешү | 2020 елның 15 феврале, алга таба – ел саен (кирәк булганда) |
| 10. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге булдыру өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында игълан | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Сатып алулар үткәрү турында белдерү | 2020 елның 1 марты |
| 11. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәгенең штат җәдвалын раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2020 елның 1 марты |
| 12. | Федераль оператор үткәрә торган программалар буенча «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | Квалификация күтәрү турында таныклык һәм кадрларны яңадан әзерләү программалары турында хисап | Федераль оператор җибәрә торган аерым график нигезендә |
| 13. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге сайтын булдыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Сайтны файдалануга тапшыру турында акт | 2020 елның 1 мае |
| 14. | Мәгариф программасын раслау | «IT-куб» цифрлы белем | Локаль актлар | 2020 елның 1 июне |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | бирү үзәге», Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | | |
| 15. | Белем бирү оешмалары мәйданчыкларын «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәгенең фирма стиленә туры китерүне тәмамлау (җиһазлар китерү, урнаштыру, җайга салу) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Эшләрне кабул итү актлары, товар накладнойлары һ. б. | 2020 елның 20 августы |
| 16. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәгенең балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә лицензия алу (кирәк булганда) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия | 2020 елның 25 августы |
| 17. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге программалары буенча белем алучы балалар җыелмасын тәмамлау | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге локаль актлары | 2020 елның 30 августы |
| 18. | Методик рекомендацияләр нигезендә «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген булдыру буенча чараларны гамәлгә ашыру барышына мониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яисә федераль оператор билгеләгән форма буенча | 2020 елның 1 марты, 2020 елның 1 июне, 2020 елның 30 августы |
| 19. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге эшли башлау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктырту | 2020 елның 1 сентябре |
| 20. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге укучылары өчен федераль операторның мәҗбүри чараларын исәпкә алып чаралар планын раслау | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге локаль актлары | 2019 елның 1 декабре |
| 21. | Бердәм көндә «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәген ачу | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге, Татарстан Республикасы | Массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктырту | Федераль оператор тарафыннан билгеләнә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Мәгариф һәм фән министрлыгы | | |

Оештырыла торган «IT-куб»
цифрлы белем бирү үзәге
тасвирламасына 1 нче
кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 22 апрель, 318 нче
карары редакциясендә)

«Әлмәт политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында төзелә торган «IT-куб» балаларга цифрлы белем бирү үзәге өчен индикаторлар таблицасы

| т/с | Индикатор/күрсәткеч исеме | 2020 елдан башлап елга минималь мәгънәсе | Мәгънәсе | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге базасында өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча мәгариф оешмасын (федераль бюджет) һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты бюджетлары, һәм (яисә) җирле бюджетлар, һәм (яисә) оешма акчалары исәбеннән белем алучы 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар саны, кеше | 400 | 400 | 500 | 600 |
| 2. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәгенең өстәмә һөнәри программалар буенча ел саен укуларын узган педагогик хезмәткәрләре өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге базасында чараларда, акцияләрдә, мастер-классларда, воркшопларда һ. б. катнашкан балалар саны, кеше | 1500 | 1500 | 1700 | 2000 |
| 4. | Өстәмә белем бирү программалары саны, берәмлек | 6 | 6 | 7 | 8 |
| 5. | «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге | 6 | 6 | 8 | 10 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | базасында үткәрелгән проектлар өстендә команда эше барышында төрле өлкәләрдә эшләү күнекмәләрен үстерә торган проект олимпиадалары, хакатоннар һәм башка конкурс чаралары саны, берәмлек | | | | |

---

Оештырыла торган «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге тасвирламасына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 22 апрель, 318 нче карары редакциясендә)

«Әлмәт политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында «IT-куб» цифрлы белем бирү үзәге эшчәнлегенә операцион чыгымнарның алдан калькуляциясе

(мең сум)

| Чыгымнар статьялары | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
|---|---|---|---|
| Эш хакы (шул исәптән НДФЛ) | 3 900 | 11 780,4 | 11 780,4 |
| Балаларга һәм аларны озатып йөрүчеләргә командировка чыгымнары (транспорт хезмәтләре, яшәү хезмәтләре һәм ярышларда / чараларда катнашу өчен тәүлеклеклек) | 400 | 1400 | 1 400 |
| Остазларга / педагогларга командировка чыгымнары (транспорт хезмәтләре, яшәү хезмәтләре һәм белем бирү сессияләрендә һәм башка чараларда катнашу өчен тәүлеклек) | 140 | 1 019,6 | 1 019,6 |
| Матди запасларның бәясен арттыру (чыгым материаллары сатып алу) | 330 | 500 | 500 |
| Башка чыгымнар (аренда, коммуналь түләүләр, җиһазларга һәм техникага хезмәт күрсәтү һ. б.) | 230 | 300 | 300 |
| Барысы | 5 000 | 15 000 | 15 000 |
| Барлыгы | | | 35 000 |

---